**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

**22 октябрь 2019 ел** **№ 35**

«Хатаны төзәтү турында»

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнебәш авыл җирлеге Башлыгының 2019 елның 18 октябрендәге 35 номерлы карарының 1 пунктында киткән хаталар белән бәйле рәвештә, Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Шилнебәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнебәш авыл җирлеге Башлыгының 2019 елның 18 октября «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнебәш авыл җирлеге Тогаево авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 35 номерлы карарының 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. 2019 елның 30 октябрь 15.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Шилнебәшавыл җирлеге Тогаево авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Шилнәбаш авыл җирлеге башлыгы О. А. Гончарова